ДОКУМЕНТ ПОДПИСАН
ЭЛЕКТРОННОЙ ПОДПИСЬЮ
СВЕДЕНИЯ О СЕРТИФИКАТЕ ЭП
Сертификат: 0CA083002FB2F5BA4FD9C1DF9EEB5D21
Владелец: Мирзаянова Рания Сагитовна
Действителен с 21.11.2024 до 21.02.2026

Раслыйм:
Күҗәкә төп гомуми
белем бирү мәктәбе директоры
Р.С.Мирзаянова:

# Татарстан Республикасы
# Актаныш муниципаль районы
# Кужәкә балалар бакчасы
# мәктәпкәчә белем бирү учреждениесенең
# 2025 – 2026 нче уку елына
# укыту-тәрбия планы

Пед.киңәшмәдә кабул ителде
Протокол №
«____» 2025 ел

# Еллык планның эчтәлеге:

I. **Балалар бакчасында 2024-2025 тәрбия һәм белем бирү эшенә методик анализ**

II. **2025-2026 уку елына төп бурычлар**

III. **Кадрлар белән эш**

IV. **Педагогик оештыру эшләре**

V. **Әти-әниләр белән эш**

VI. **Мәктәп белән элемтәле эш**

VII. **Административ-хуҗалык эшләре**

VIII. **Балаларны сәламәтләндерү буенча эш планы**

IX. **Алга таба бурычлар**

# Балалар бакчасының 2024-2025 елына тәрбия һәм белем бирү эшенә методик анализ

Балалар бакчасында тәрбия һәм белем бирү эшен оештыру өчен тиешле шартлар тудырыла, кирәкле әсбаплар һәм җиһазлар булдырыла. Җиһазларны урнаштыру куркынычсызлык һәм санитария – гигиена таләпләренә туры килерлек итеп урнаштырырга тырышабыз.

Матур әдәбият, язучылар иҗаты почмагы оештырылган, махсус үрнәкләр урнаштырылган. Милли почмак булдырылган. Табигатьне күзәтү календаре бар. Балалар белән индивидуаль эш өчен программа буенча физкультура почмаклары җиһазландырылган. Акыл эшчәнлеген үстерү бөтен төр эшчәнлектә тормышка ашырыла, ләкин төп формасы эшчәнлек булып санала.

Эшчәнлек барышында тәрбияче күрсәтмә әсбаплар куллана, төркемдә шөгыльләр уен рәвешендә үткәрелә. Шулай ук тәрбияче халык авыз иҗатын киң куллана. Халкыбызның әхлакый идеаллары булган хезмәт сөючәнлек, өлкәннәргә ихтирам, әдәплелек, дуслык, туган илгә, туган җиргә, табигатькә мәхәбәт хисләрен татар халык педагогикасын кулланып тәрбиялибез.

2024-2025 уку елында балалар бакчасы 5 бала белән комплектлаштырылып уку елы дәвамында 4 бала белән эш алып барды. Бу уку елында коллектив үз алдына балаларның физик сәламәтлекләрен саклау, ныгыту, һәрбер баланы игътибар белән карау, тәрбияләү, яшь үзенчәлекләрен исәпкә алып нәниләрне мәктәпкә әзерләү, һәрдаим ата-аналар белән элемтәдә тору максатын куйды.

Балалар бакчасында тәрбия һәм белем бирүдә милли кыйммәтләр һәм традицияләрне исәпкә алып, баланың рухи-әхлакый һәм эмоциональ тәрбиясенә зур әһәмият бирелде. Тәрбия һәм белем баланы кешелек культурасының төп компонентларына (кузаллау, белем, мораль, сәнгать, хезмәт) якынайту процессы буларак кузалланылды.

Коллектив алдында :

- балаларның сәламәтлекләрен ныгыту өстендә эш алып бару;
- физкультура сәламәтләндерү эшләрендә педагогларның һөнәрилеген, тәрбия һәм белем бирү процессының сыйфатын күтәреп, балаларның физик үсешен камилләштерү;

фикер йөртү сәләтләрен камилләштерү, үстерешле тәрбия биреп мәктәп алды әзерлеге үткәрү; -юл хәрәкәтен өйрәтүдә ата-аналар белән эш алып барып транспорт культурасы булдыру;

-мәгълүмәти –коммуникатив технологияләрне киң кулланып педагогларның һөнәри осталыкларын арттыру бурычларын куйды. Шушы бурычларны хәл итү буенча бакчада еллык план төзелеп, план нигезендә эш алып барылды.

Коллективта 1 югары белемле педагог хезмәт куйды.

Педагог район һәм курс методик берләшмәләрдә үз белемнәрен күтәрде:

Тәрбияче һәм мөдир системалы үз белемнәрен күтәрү өстендә эш алып бардылар, район буенча үткәрелгән РМО ларда, киңәшмәләрдә катнашып, алдынгы эш тәҗрибәсен өйрәнделәр һәм аларда алган белемнәрне үз эшләрендә кулланалар.

Мөдир, район буенча планлаштырылып үткәрелгән барлык киңәшмәләргә катнашты, үзенең фикерләре белән уртаклашты.

Программа үтәлеше
Уртанчылар төркемендә 100%.
Мәктәпкә әзерлек төркемендә 100%
Авыр гаилә - юк. 3 бала ата-аналар түләвенең 50% ташламасыннан файдаланды.
Бакча хезмәткәрләре ата-аналар белән һәрвакыт элемтәдә тора. Ел дәвамында 3 гомуми җыелышлар уздырдык һәм ачык ишекләр көненә чакырып, сөйләшүләр үткәрдек, ата-аналар һәм балалар белән,мәктәп белән берлектә һәрдаим бергәләп бәйрәмнәр уздырырга тырыштык.

Балалар бакчасы балаларны ике дәүләт теленә өйрәтү буенча ел да ныклы эш алып барыла. Ел дәвамында балаларны ике дәүләт теленә өйрәтү буенча яңа укыту-методик комплектлар, ИКТ кулланып эзлекле эш алып барылды. Балаларны ике дәүләт теленә өйрәтүне тормышка ашыру максатыннан еллык эш планы,перспектив планнар төзелде һәм план нигезендә даими эш алып барылды. Балалар бакчасы ата-аналар белән тыгыз элемтәдә эшләде. Әти-әниләр белән эш системалы планга нигезләнеп алып барыла. Уку елы барышында төрле формадагы эшләр алып барылды. Әти-әниләр белән берлектә системалы рәвештә бәйрәм иртәләре, күңел ачу кичәләре оештырылды һәм үткәрелде.
Рус телен гаиләдә дә, бакчада да өйрәнү йөзеннән ата-аналар һәм балалар белән берлектә рус һәм татар халык әкиятлере буенча рәсем конкурсы узды.
Әти-әниләр һәм балалар белән берлектә балалар арасында рус һәм татар халык шигырьләрен, җырларын сәнгатьле итеп сөйләү буенча бәйгеләр үтте.
УМК почмагында яңа укыту-методик комплектлар махсус тартмаларга тутырылды, һәр тартмага номер куелып картотека булдырылды.
Бу почмакта барлык методик комплектлар, аудио-видео материаллар, мультимедиопроекторлар, экраннар тупланган. Бакчабызда проектор, ноутбук бар, эшчәнлектә ИКТ еш кулланабыз. Балаларга интернеттан һәр эшчәнлек өчен тулы мәгълүматлар тупланды, тәрбияченең “методик копилка”сы булдырылды.
Ел дәвамында план нигезендә балаларга ике дәүләт телен өйрәтү буенча бакчада тематик тикшерүләр үткәрелде һәм педагогик киңәшмәдә нәтиҗәләр ясалды. Тәрбияче балаларны ике дәүләт теленә өйрәтү буенча әти-әниләр алдында әңгәмәләр үткәрде.
Тәҗрибәбезне уртаклашу максатыннан бакчабызда уку елы башыннда ук “Балалар бакчасында ФГОС ка нигезләнеп үстерешле тирәлек” дигән тема башлангыч сыйныф укытучылары белән киңәшмә уздырдык һәм тәрбияче Салахова Д.И. дәрес күрсәтте .

Документ создан в электронной форме. № 121 от 06.12.2025. Исполнитель: Мирзаянова Р.С.
Страница 89 из 170. Страница создана: 06.12.2025 11:30
ЭЛЕКТРОННЫЙ ТАТАРСТАН

***Балалар бакчасы каршында туган кыенлыклар һәм каршылыклар***.
1) Төркемдә төрле яшьтәге балалар булу, дәресләр үткәрүдә кыенлыклар тудыра.
2)Финанс кыенлыклары материаль- техник базаны ныгытуда комачаулый.
Шулай ук балаларга уйнар өчен уен площадкасын да тулыландырырга, яңартырга кирәк.
**Бакчаның исеме:**
**Адрес:** 423734, ТР, Актаныш муниципаль районы, Күҗәкә авылы, Совет урамы 46 йорт.
**Электрон почтаның адресы:** Shaykhetdinova1972@mail.ru

**Төркемнәр саны:** төрле яшьтәге балалар төркеме
**Балалар саны**: 5 бала.

**Бакча мөдире** **Шайхетдинова Гөлшат Шаех кызы**
Педагогик стажы: 24 ел
Бу вазыйфада: 10 ел

**Тәрбияче** **Салахова Дания Исмагил кызы**
Педагогик стажы: 44 ел
Бу вазыйфада: 5 ел

## Педагогларны аттестацияләү

| **№** | **Ф.И.О.** | **Вазыйфасы** | **Белеме** | **Пед. стаж** | **Квалификацион категория** | **Соңгы аттестация** |
|---|---|---|---|---|---|---|
| 1 | Шайхетдинова Г.Ш. | мөдир | югары | 24 | | 2023 |
| 2 | Салахова Д.И. | тәрбияче | югары | 44 | 1 | 2024 |

Балалар бакчасы түбәндәге **программалар** буенча эшли**:**
Р.К.Шаехова «Региональная программа дошкольного образования» , Казань, 2012;
Н.Е.Веракса, Т.С. Комарова Примерная основная общеобразовательная программа дошкольного образования «От рождения до школы», Москва.Мозаика- Синтез, 2012.
**Парциаль программалар:**
Ф.В.Хәзрәтова, З.Г.Шәрәфетдинова “Туган телдә сөйләшәбез” 2-3 яшьлек балаларны туган телдә сөйләшергә өйрәтү буенча методик ярдәмлек, Казан “Фолиант”, 2012;

Ф.В.Хәзрәтова, З.Г.Шәрәфетдинова “Туган телдә сөйләшәбез” 3-4 яшьлек балаларны туган телдә сөйләшергә өйрәтү буенча методик ярдәмлекКазан “Фолиант”, 2012;
Ф.В.Хәзрәтова, З.Г.Шәрәфетдинова “Туган телдә сөйләшәбез” 4-5 яшьлек балаларны туган телдә сөйләшергә өйрәтү буенча методик ярдәмлек, Казан “Фолиант”, 2012;
З.М.Зарипова, Л.Н.Вәҗиева “Туган телдә сөйләшәбез” 5-7 яшьлек балаларны туган телдә сөйләшергә өйрәтү буенча методик ярдәмлек, Казан “Фолиант”, 2012;
С.М.Гаффарова, Д.С.Гарипова “Изучаем русский язык” методическое пособие для воспитателей детских садов 4-5 лет, 5-6 лет, 6-7 лет;
С.М.Гаффарова, Д.С.Гарипова “Изучаем русский язык”: программа, методические рекомендации, диагностика, Казань, 2013;
Р.К.Шаехова Мәктәпкәчә балалар әлифбасы: “Авазларны уйнатып” , Казан,2011;
Р.К.Шаехова “Занимательное обучение татарскому языку, Казан, 2011.
К.В.Закирова “Балачак аланы”, балалар бакчалары тәрбиячеләре өчен хрестоматия, Казан, 2011;
К.В.Закирова “На поляне детства”, хрестоматия для воспитателей детских садов, Казан, 2011;
К.В.Закирова “Балачак- уйнап-көлеп үсәр чак”, Казан,2012;
К.В.Закирова “Уйный-уйный үсәбез”, Казан,2005;
К.В.Закирова, Л.Р.Мортазина “Әй уйныйбыз, уйныйбыз”, балалар бакчалары тәрбиячеләре һәм физкультура инструкторлары өчен методик кулланма, Казан, 2013;
К.В.Закирова, Р.Ә. Кадыйрова “Балалар бакчасында әдәп-әхлак тәрбиясе” Казан,2013;
Р.К.Шаехова Мәктәпкәчә яшьтәгеләр әлифбасы “Авазларны уйнатып”. 1-2 кисәкләр, Казан,2011;
Р.А.Борһанова “Туган як табигате белән таныштыру”;
Л.З.Галиуллина, Д.Г.Мансурова “Программа по обучению детей русскому языку”, Набережные Челны, 2004
Г.А.Галеева, С.М. Гаффарова “Мәктәпкәчә яшьтәге балаларны юлларда үзләрен хәвефсез тоту кагыйдәләренә өйрәтү дәресләре циклы”, Казан,2010;
З.Г.Шәрәфетдинова, И. Җ. Хәбибуллина, Ф. В. Хәзрәтов “**МАТЕМАТИКАГА ӨЙРӘНӘБЕЗ**”

# I. 2025-2026 уку елына төп бурычлар

1.**ФОП** ка таянып балалар бакчасында һәр балага сыйфатлы мәктәпкәчә белем бирү өчен бертигез шартлар тудыру,информацион-коммуникатив технологияләр, мультимедия ресурсларын куллануны дәвам итү.

2.Мәктәпкәчә белем бирү процессына балаларны **Татарстан Республикасының ике хөкүмәт теленә өйрәтүдә яңа укыту методик комплектларын куллануны дәвам итү.**

3.Бакча, гаилә һәм мәктәп арасындагы бәйләнешне үстерү һәм балалар тәрбияләүдә куллануны дәвам итү.

4.Балаларга туган якнын тере һәм тере булмаган табигатенә сакчыл караш тәрбияләү; үзеңнең катнашыңнан соң туган уңай һәм тискәре нәтиҗәләрне алдан күрә белергә өйрәнү, табигатьне кирәксезгә куланмау һәм аны дөрес файдалануның беренчел күнекмәләрен формалаштыруны дәвам итү.

# II. Кадрлар белән эш

| Эш төре | Үтәлеш вакыты |
|---|---|
| 1. Инструктажлар үткәрү<br>– хезмәтне саклау буенча;<br>– янгын куркынычсызлыгы чараларын үтәү буенча;<br>– балаларның тормышын һәм сәламәтлеген саклау буенча;<br>– терроризмга каршы<br>_короновируска каршы<br><br>2. Производство киңәшмәләре уздыру<br>а)Еллык план кабул итү, хезмәтне үтәү кагыйдәләре (правила внутреннего трудового распорядка)<br>б)Кышкы чорда учреждениенең эшчәнлеге (җылылык һәм электр режимын саклау; Яңа ел бәйрәмнәрен үткәрү, каникуллар чорына дежурлык графигын төзү һәм раслау турында сөйләшү)<br>в)Хезмәтне саклау һәм техника куркынычсызлыгы кагыйдәләренең үтәлеше (рейд нәтиҗәләре турында сөйләшү), 8 Март бәйрәмен үткәрү<br>г) “Бакчаның матурлыгы – барыбызның да эше.” (Өмәләр үткәрү, чәчәк һәм яшелчә орлыклары утырту, мәктәп территориясен матурлау – җәйге эш режимы турында сөйләшү)<br><br>3. Тәрбиячеләрнең үзбелем планнары, квалификация күтәрү буенча эш планнарын төзү, план буенча эш алып бару<br><br>4. Коллективның иҗтимагый эшчәнлеге<br>– Өлкәннәр һәм тәрбиячеләр көнен уздыру (коллективның ветераннарын хөрмәтләү)<br>– Яңа ел бәйрәмен уздыру<br>– 8 Март бәйрәмен уздыру, ветераннарны чакыру<br>–авыл территориясен җыештыру һ.б. эшләрдә актив | Август<br><br>Сентябрь<br>Декабрь<br><br>Март<br><br>Май<br><br>Ел дәвамында<br><br>Октябрь<br><br>Декабрь<br>Март<br>Май<br><br>Ел дәвамында |


ЭЛЕКТРОННЫЙ ТАТАРСТАН

| | |
|---|---|
| катнашу<br><br>5. Ярдәмче персонал белән консультацияләр, аңлату эшләре<br>– хезмәтне үтәү инструкцияләре<br>– кече тәрбиячеләрнең укыту-тәрбия эшендәге роле<br>– СанПиН кагыйдәләрен үтәү, бинаның чисталыгы турында сөйләшү<br>– кече тәрбиячеләрнең җәйге сәламәтләндерү эшендә роле | |

# III. Педагогик оештыру эшләре

| | |
|---|---|
| **Педсоветлар**<br>*1. Яңа уку елына әзерлек*<br>– җәйге сәламәтләндерү эшенә йомгак ясау<br>– яңа уку елына эш планын кабул итү һәм раслау<br>– турыдан-туры белем бирү эшчәнлек челтәрен төзү һәм раслау<br>– программаларны раслау<br>– уку елы башында балаларның белеме һәм сәламәтлеге торышын тикшерү турында сөйләшү | Август |
| *2. Балалар бакчасында ике теллелек*<br>– Мәктәпкә әзерлек төркемендә рус теле эшчәнлеген карау. Тәрбияче – Ямалиева А.Ф.<br>“Изучение организации работы в ДОУ по обучению детей русскому языку”<br>– белем бирү эшчәнлегендә яңа технологияләр куллану. Чыгыш ------------------------<br>– Балаларның туклануына һәм сәламәтлеге торышына анализ нәтиҗәләре белән танышу.<br>– «Ачык ишекләр көне» уздыру турында сөйләшү | Ел дәвамында<br><br>Ел дәвамында |
| *3.* Баланы мәктәпкә әзерләү – безнең бурычыбыз<br>-Ачык ишекләр көне үткәрү.<br>-“Баланы мәктәпкә әзерләү – безнең бурычыбыз”. Башлангыч класс укытучысы белән берлектә мәктәпкә әзерлек балаларының әзерлек торышы белән танышу. | Апрель |
| *4. Йомгаклау*<br>– Еллык эш нәтиҗәләре белән танышу | Май |

| | |
|---|---|
| – Җәйге сәламәтләндерү буенча эш планын төзү һәм раслау | |
| – Чыгарылыш кичәсен уздыру турында сөйләшү | |
| – 2025-2026 елның план проектын карау | |
| **Ачык эшчәнлек карау, тәҗрибә уртаклашу** | |
| 1.Мәктәпкә әзерлек төркемендә рус теле эшчәнлеген карау. Тәрбияче – Салахова Д.И. | |
| 2. Ачык ишекләр көне | |
| **Конкурслар, күргәзмәләр** | |
| «Безнең эшләр» – әти-әниләр белән кул эшләре | |
| «Көзге бәйрәм» - бәйрәменә күргәзмә оештыру | Ноябрь |
| «Исәнме, чыршы!» – бәйрәмгә бүлмәләрне бизәү, маскалар әзерләү. | Декабрь |
| «Әти белән көчле мин» – рәсем күргәзмәсе | Февраль |
| «Әниләр алтын кебекләр» Балалар рәсемнәре күргәзмәсе | Март |
| «Без сугыш теләмибез!» Балалар һәм әти-әниләр белән Бөек Җиңүнең 81 еллыгына рәсем конкурсы үткәрү. | Май |
| **Бәйрәмнәр** | |
| «1 сентябрь – Белем бәйрәме». | Сентябрь |
| «Көзге бәйрәм!» | Ноябрь |
| «Әниләр көне» | Ноябрь |
| «Исәнме, чыршы!» | Декабрь |
| «Кышкы спартакиада» | Январь |
| «23 февраль - Ватанны саклаучылар көне» “Әти белән көчле мин” | Февраль |
| «8 Март – Халыкара хатын-кызлар көне»”Әниләр алтын кебекләр” | Март |
| «Хуш киләсең, Нәүрүз!» | Апрель |
| «Тукай – безнең күңелләрдә» | Апрель |
| «9 Май – Бөек Җиңү көне» | Май |
| «Сау бул, бакча!» | Май |
| «Милли бәйрәм – Сабантуе» | Июнь |
| **Экскурсияләр** | |
| 1.Һәр ел фасылында табигатькә экскурсияләр: иген басуына, елга - чишмә буена, тауга бару. | |
| 2. Мәдәният йортына ,китапханәгә,мәктәпкә һәм музейга | |


ЭЛЕКТРОННЫЙ ТАТАРСТАН

| | |
|---|---|
| экскурсияләр<br><br>**Сәламәтләндерү эше**<br><br>1.Иртәнге гимнастика, физкультура эшчәнлеген,прогулкаларны тиешле югарылыкта оештыру.<br>2.Чыныктыру процедураларын үткәрү (һава ванналары, массаж тренажерында шөгыльләнү һ.б.)<br>3.Балалар белән йомшак мөгамәләдә булу, уңай психологик климат тудыру.<br>4.Адаптация чорында балага аеруча игътибарлы булу.<br>5.Туклануны тиешле дәрәҗәдә оештыру, нормаларның үтәлешен контрольдә тоту.<br>6.Балаларның сәламәтлеген һәм үсешен тикшереп тору.<br>7.Шәфкать туташының балалар, тәрбиячеләр һәм әти-әниләр белән әңгәмәләрен, консультацияләрен оештыру, (“Салкын тисә”, “Өч яшьтә була торган кризис чоры”, “Әгәр балагыз телевизорны күп караса!”, “Беренче ярдәм күрсәтү” һ.б.)<br><br>**Контроль**<br><br>Тематик тикшерү<br>1.ФГОС буенча эшләү шартларында мәктәпкәчә белем бирү процессына балаларны ике телгә өйрәтүдә яңа укыту методик комлектларын куллану узенчәлекләре<br>– тәрбияче лаборатория<br>– балаларның белемнәре<br><br>Оператив тикшерү<br>1.Группаларның яңа уку елына әзерлеге.<br>2.Эчке тәртип кагыйдәләренең үтәлеше<br>3.Балаларның мөстәкыйль эшчәнлеге өчен шартлар<br>4.Прогулкаларны үткәрүнең торышы<br>5.Эшчәнлекләрдә балаларның куркынычсызлыгын тәэмин итү | |

## IV. Әти-әниләр белән эш

| | |
|---|---|
| 1.Яңа әти-әниләр белән договорлар төзү,укыту- тәрбия эшендә яңа буын программаларын, **укыту методик комплектларны** куллану. | Август<br><br>Сентябрь<br>Октябрь |

| | |
|---|---|
| 2.Көзге табигатькә экскурсияләр оештыру.<br>3.«Көзге сезонда балаларның сәламәтлеген саклау».Әти-әниләр почмагын тулыландыру, әңгәмә.<br>4.Анкеталар уздыру.<br>5.Яңа ел бәйрәмнәрен уздыруда әти-әниләрне җәлеп итү. Ата-аналар комитетының утырышы. | Ноябрь<br>Декабрь |
| 6.«Балагыз мәктәпкә барырга әзерме?» Әңгәмә, информацияон стенд ясау. | Январь |
| 7.«Кышкы чорда балаларның сәламәтлеген саклау». Әңгәмә, күчмә папкага информация.<br>8.«Әти белән көчле мин». Рәсем күргәзмәсе<br>9.«Әниләр алтын кебекләр» Балалар рәсемнәреннән күргәзмә. | Февраль<br>Март |
| 10.Курчак киемнәре тегү, уенчыкларны төзәтү эшенә әти-әниләрне җәлеп итү<br>11. Территорияне җыештыру, өмә уздыру**.** | Апрель<br>Май |
| 12. Яшелчәләр, чәчәк орлыклары утыртуда әти-әниләрнең ярдәмен оештыру.<br>13.Ата-аналар комитетының эшенә йомгак ясау, утырыш. | Май |
| **14.Әти-әниләр почмагында “Изучаем русский язык”, “Туган телдә сөйләшәбез” рус телендә һәм туган телдә санамышлар, шигырьләрне ятлауда әти-әниләргә тәкъдим ителгән шигырьләр ширмаларын яңарту.**<br>*Гомуми җыелышлар*<br>1.Яңа уку елы белән! “Транспорт хәрәкәте вакытында балаларның тән җәрәхәте алулары”<br>– Узган уку елы нәтиҗәләре, җәйге сәламәтләндерү эшенә йомгак( **эшләгән булсак**)<br>– Яңа уку елына бурычлар<br>– Ата-аналар комитетын сайлау, эш планын раслау<br>-“Балаларга белем һәм тәрбия бирүдә федераль дәүләт белем стандарты ”<br>Мәктәпкәчә белем бирү процессына балаларны Татарстан Республикасының ике хокумәт теленә өйрәтүдә яңа укыту методик комплектларын куллану. | Август<br><br><br><br><br><br><br><br><br><br><br>Ноябрь |
| 2.«Балага бәйрәм оештыра белү сәнгате»<br>– «Балага өйдә музыка тыңлау буенча киңәшләр»<br>– Без гаиләдә бәйрәмнәрне ничек уздырабыз? Фикер алышулар, әти-әниләр чыгышы<br><br>– Туклану нормаларының үтәлеше.<br>3.Уку елы нәтиҗәләре<br>– Узган уку елына йомгак ясау, актив әти-әниләргә рәхмәт белдерү | <br><br><br><br>Май |


ЭЛЕКТРОННЫЙ ТАТАРСТАН

| | |
|---|---|
| – Җәйге сәламәтләндерү буенча эш планы белән таныштыру(**эшләсәк)**<br>– Җәйге чорда балаларның тормышын саклау һәм куркынычсызлыгын тәэмин итү буенча әти-әниләргә киңәшләр | |

## Vl. Дәвамчанлык буенча балалар бакчасы һәм мәктәп арасында эш планы

| | |
|---|---|
| Мәктәп белән бердәм эш планы төзү<br>1 сентябрь – Белем бәйрәменә (мәктәп турында мәгълүмәт бирү).1класска укырга керүче балаларның интеллектуаль үсешен диагностикалау.<br>Өлкәннәр төркеменә йөрүче балаларның әти-әниләре өчен лекция”Булачак укучының көндәлек режимын оештыру.Баланы мәктәпкә укырга әзерләү.”<br>Башлангыч класс укучыларын “Көзге бәйрәм” гә чакыру.<br>Ата-аналар җыелышы “Баланың физик яктан сәламәтлеге.Спорт уеннары.”<br>“Әкият көне” уздыру, башлангыч класс укучыларын чакыру<br>“Батырлык дәресе”<br>Грамотага өйрәнү һәм математикадан ачык шөгыльләр.<br>“Тәрбиядә уен алымнары”дигән темага доклад<br>Мәктәпкә экскурсия.Балаларны ирекле аралашу вакытында күзәтү.<br>Әлифба бәйрәмендә катнашу<br>“Бөек Җиңүгә 80 ел”<br>“Соңгы кыңгырау”, “Сау бул, бакча!” Чыгарылыш бәйрәмнәрендә катнашу<br>Берләшмә утырышы”Балалар бакчасы һәм мәктәп эшендә дәвамчанлык:проблемалар,уңышлар.” | Август<br>Сентябрь<br><br><br>Октябрь<br><br><br>Ноябрь<br>Декабрь<br><br>Январь<br><br><br><br>Апрель<br><br><br>Май<br>Май |

## V. Административ-хуҗалык эшләре

| | |
|---|---|
| 1.Яңа уку елына әзерлек эшләрен тәмамлау<br>2.Җылылык сезонына әзерлек, территорияне җыештыру-мәктәп белән<br>3.Янгын сүндерү җиһазларының торышын барлау<br>4.Территорияне тәртиптә тоту, кардан арындыру, яшелчәләрнең торышын барлау мәктәп белән<br>5.Температура һәм электр энергиясен сак тоту<br>6.Территорияне җыештыру, чәчәкләр утырту | Август<br>Октябрь<br>Ноябрь<br>Декабрь-<br>Март<br>Апрель<br>Май<br>Июнь-июль |

| | |
|---|---|
| мәктәп белән<br>7.Бакча эшләре- мәктәп белән<br>8.Яңа уку елына әзерлек | Август |

**СЕНТЯБРЬ АЕ**

| Эш төре | Җаваплы |
|---|---|
| **I.Кадрлар белән эш**<br>*1. Производство киңәшмәсе уздыру. “Хезмәтне үтәү кагыйдәләре” (“Правила внутреннего трудового распорядка”)*<br>– эшчеләр өчен эш кагыйдәләрен аңлату (должностные инструкции)<br>– хезмәтне саклау һәм пожар, техника куркынычсызлыгы кагыйдәләрен саклау буенча инструктаж үткәрү<br>– балаларның тормышын һәм сәламәтлеген саклау буенча инструктаж үткәрү, җаваплыларны билгеләү<br>2.Тәрбиячеләрнең үз белем планнарын төзү.<br>3. Оператив тикшерү<br>4.Кече тәрбияче һәм пешекче белән санэпидрежим турында сөйләшү | тәрбияче.<br><br>тәрбияче, |
| **II.Педагогик оштыру эшләре**<br>1 *Педкиңәшмә. “Яңа уку елына әзерлек*”<br><br>– яңа уку елына эш планын кабул итү һәм раслау<br>– эшчәнлек челтәрен төзү һәм раслау<br>– укыту программаларын раслау<br>– уку елы башында балаларның белемен һәм сәламәтлеген тикшерү турында сөйләшү<br>2.Яңа уку елына әзерлек эшләрен тәмамлау<br>3.Белем бәйрәме –мәктәпкә карарга керү<br>4.Көзге табигатькә экскурсияләр оештыру: иген басуына,<br>чишмә буена<br>5.Әти-әниләр почмагын тулыландыру | Тәрбияче,<br><br>Тәрбияче |
| **III.Әти-әниләр белән эш**<br>1.Яңа әти-әниләр белән договорлар төзү, Устав белән таныштыру<br>2.Гаиләләргә анализ ясау(тулы булу-булмавы, әти-әниләрнең белем дәрәҗәсе, эш урыны һ.б.) | Тәрбияче. |


ЭЛЕКТРОННЫЙ ТАТАРСТАН

| | |
|---|---|
| 3.Әти-әниләр белән берлектә көзге табигатькә экскурсияләр оештыру<br>4.”Транспорт хәрәкәте вакытында балаларның тән җәрәхәте алулары”. Гомуми җыелыш.<br>– җәйге сәламәтләндерү эшенә йомгак, яңа уку елына бурычлар<br>– Ата-аналар комитетын сайлау, эш планын раслау<br><br>**IV.Административ-хуҗалык эшләре**<br>-Яңа уку елына әзерлек эшләрен тәмамлау<br>-Группадагы мебельне маркировкалау<br>-Приказлар, положениелар эшләү<br>-Агымдагы эшләр | |

**ОКТЯБРЬ АЕ**

| Эш төре | Җаваплы |
|---|---|
| **I.Кадрлар белән эш**<br>1. Оператив.Эчке тәртип кагыйдәләренең үтәлешен тикшерү<br>2.Өлкәннәр көнен билгеләп үтү турында сөйләшү, коллективның ветераннарын хөрмәтләү—<br>**мәктәп белән бергә**<br><br>**II.Педагогик оештыру эшләре**<br>1.Табигать почмагында эшне оештыру.Консультация –<br>2. Ата-аналар почмагын файдалы мәгълүмат белән тулыландыру: “Балаларның яшь үзенчәлекләре”, “Сезонга карап киендерү” һ.б.<br>3.“Көзге матурлык”. Көз бәйрәменә табигый материаллардан һәм чәчәкләрдән күргәзмә ясау<br>4.“Көзге бәйрәм!” Бәйрәм иртәсе уздыру<br>5.Балалар белән чәчәк орлыкларын җыю, чәчәклектә эшләү<br>6.Көз темасына рәсемнәр, кул эшләре ясау, балалар эшләреннән күргәзмә оештыру<br><br>**III.Әти-әниләр белән эш**<br><br>-”Көзге муллыктан” – аукцион уздыру<br>-Ата-аналар почмагын мәгълүмат белән баету: “Сезонга карап киендерү,” | Тәрбияче.<br><br>Тәрбияче.<br>Тәрбияче.<br><br>Тәрбияче.<br><br>Тәрбияче.<br><br>тәрбияче.<br><br>тәрбияче. |

| | |
|---|---|
| “Бала белән өйдә шөгыльләнү” һ.б. темаларга.<br><br>**IV.Мәктәп белән элемтәле эш**<br>1.Мәктәп белән элемтәле эш планы төзү<br>2.Башлангыч класс укучыларын “Көзге бәйрәм!” бәйрәменә чакыру<br>3.Беренче класс укучыларының укуы белән кызыксыну, укытучы белән әңгәмә.<br>4.”Батырлык дәресе”<br>**V.Административ-хуҗалык эшләре**<br><br>3.Территорияне җыештыру, өмә уздыру | <br><br>Коллектив |

**НОЯБРЬ АЕ**

| Эш төре | Җаваплы |
|---|---|
| **I.Кадрлар белән эш**<br>1. Терроризмга, янгынга каршы, балаларның тормышын саклау буенча инструктажлар үткәрү.<br><br><br>**II.Педагогик оештыру эшләре**<br>1.Педагогик киңәшмә. “Балалар бакчасында ике теллелек.”<br>– Рус теленнән балалар эшчәнлеген карау.<br>– “Балалар бакчасында ике теллелекнең торышы.”<br>– Яңа укыту методик комплектларын куллануны дәвам итү.<br>– Балаларның туклануына һәм сәламәтлеге торышына анализ нәтиҗәләре белән танышу.<br>2.Көзге каникулга эш планы төзү<br>3. “Әниләр көне” уздыру<br>4.”Ачык ишекләр” көне уздыру<br>5.Балаларның сәламәтлеген саклау максатыннан чыныктыру процедуралары үткәрү<br><br>**III.Әти-әниләр белән эш**<br>1.”Ачык ишекләр” көне уздыру<br>2. “Көз көне балаларның сәламәтлеген саклау.” Әңгәмә, әти-әниләр почмагын информация белән тулыландыру<br><br>**IV.Административ-хуҗалык эшләре**<br>1.Янгын сүндерү җиһазларының торышын барлау<br>2.Мәктәп территориясен тәртиптә тотуда булышу. | <br><br>Мөдир<br><br><br><br><br><br><br>Тәрбияче.<br><br><br><br><br><br>Тәрбияче.<br>Тәрбияче.<br><br><br><br><br><br>Тәрбияче.<br>Тәрбияче.<br><br><br><br><br>Коллектив |

| | |
|---|---|
| | |

**ДЕКАБРЬ АЕ**

| Эш төре | Җаваплы |
|---|---|
| **I.Кадрлар белән эш**<br>1.Производство киңәшмәсе уздыру. “Кышкы чорда учреждениенең эшчәнлеге”<br>– оптималь җылылык режимын тәэмин итү<br>– электр ресурсларын экономияләү,<br>– Яңа ел бәйрәмнәрен уздыру чорына пожар һәм техника куркынычсызлыгы кагыйдәләрен үтәү буенча инструктаж<br>2.Оператив тикшерү. Балаларның мөстәкыйль эшчәнлеге өчен шартлар<br>3.Бәйрәм чорына кизү тору графигы төзү. | |
| **II.Педагогик оештыру эшләре**<br>1.”Кышкы чорда балаларның сәламәтлеген саклау: экскурсияләр, прогулкалар, кышкы уеннар чорында куркынычсызлык кагыйдәләрен үтәү, сезонга карап киендерү. Консультация<br>2.Яңа ел бәйрәмен уздыруга әзерлек эшләре<br>3. “Исәнме, чыршы!” Бәйрәмгә бүлмәләрне бизәү.<br>4.Кышкы уен мәйданчыкларын бизәү мәктәп белән<br>5.Паркка кышкы экскурсия оештыру<br>6.Чыныктыру процедураларын дәвам итү<br>7.”Кышкы чорда балаларның сәламәтлеген саклау” Әти-әниләр белән әңгәмә, почмакны файдалы мәгълүмат белән баету | Тәрбияче.<br><br>Тәрбияче. |
| **III.Әти-әниләр, мәктәп белән эш**<br>2. Ата-аналар комитеты утырышы. Яңа ел бәйрәмнәрен уздыру, балаларга бүләкләр алып кайту турында сөйләшү<br>3. Мәктәптә уздырылучы Яңа ел бәйрәмнәрендә катнашу, укучылар белән берлектә маскалар, декорацияләр әзерләү<br>4. Беренче класс укучыларының өлгереше белән танышу, занятиеләр, дәресләр карау, укытучы белән әңгәмә<br>5.Әти-әниләр белән берлектә уен мәйданчыкларын бизәү мәктәп белән бергә | Тәрбияче<br><br>Тәрбияче, эти-әниләр<br><br>Тәрбияче. |


ЭЛЕКТРОННЫЙ ТАТАРСТАН

| | |
|---|---|
| **IV.Административ-хуҗалык эшләре**<br>1.Территорияне тәртиптә тоту, кардан вакытында арындыру мәктәп белән бергә<br>2.Чираттагы ялларның графигын төзү, шәхси эш папкаларын тәртипләү<br>4.Еллык отчет әзерләп тапшыру | |

**ЯНВАРЬ АЕ**

| Эш төре | Җаваплы |
|---|---|
| **I.Кадрлар белән эш**<br>1.Кышкы чорда балаларның тормышын һәм сәламәтлеген саклау: бозлавык, боз сөңгеләреннән сак булу турында сөйләшү<br>2.Җылылык һәм яктылык режимын саклау<br>3.Оператив тикшерү.Прогулкаларны үткәрүнең торышы | |
| **II.Педагогик оештыру эшләре**<br>1.Тикшерү.”Балаларда сәламәт яшәү рәвеше турында күззаллау формалаштыру”<br>– тәрбияче лабораториясе<br>– балаларның белем дәрәҗәсе | Тәрбияче. |
| 2.Балалар белән Яңа ел бәйрәмнәрен ничек уздырулары турында әңгәмә<br>3. “Мин Яңа елны ничек каршыладым” – балалар рәсемнәреннән күргәзмә | |
| 4. “Кышкы спартакиада” спорт бәйрәме уздыру –**мәктәп белән бергә** | Тәрбияче. |
| 5.Әти-әниләр почмагын файдалы мәгълүмат белән тулыландыру. Тема – “Безнең балалар нәрсә белән уйныйлар” | Тәрбияче |
| **III.Әти-әниләр, мәктәп белән эш**<br>.Консультацияләр:<br>1.“Гаиләдә балада хезмәткә уңай мөнәсәбәт тәрбияләү”<br>– “Бала өйдә нинди хезмәтләр башкара”. Фикер алышулар<br>2. “Кышкы чорда юлларда куркынычсызлыкны тәэмин итү” – әңгәмә<br><br>Мәктәпкә хәзерлек балаларның мәктәптә эшчәнлекләрен оештыру | Тәрбияче |

| | |
|---|---|
| **IV.Административ-хуҗалык эшләре**<br>1.Территорияне тәртиптә тоту, түбәне чистарту **мәктәп белән бергә**<br><br>2.Электр челтәренең торышын тикшерү, төзекләндерү өчен кирәкле материалларны барлау **мәктәп белән бергә**<br>3.Агымдагы эшләр | |

**ФЕВРАЛЬ АЕ**

| Эш төре | Җаваплы |
|---|---|
| **I.Кадрлар белән эш**<br>1.Эшчәнлек вакытларында балаларның иминлеген саклау һәм техника куркынычсызлыгы кагыйдәләренең үтәлешен тикшерү<br>2.СанПиН кагыйдәләрен үтәү, бинаның чисталыгын саклау турында кече тәрбияче белән консультация.<br>3. Оператив тикшерү | Тәрбияче. |
| **II.Педагогик оештыру эшләре**<br>1.15 февраль – М.Җәлилнең туган көнен билгеләп үтү<br>2. 21 февраль – Туган тел көнендә авыл китапханәсенә экскурсия<br>3.Ватанны саклаучылар көнен билгеләп үтү, әтиләргә бүләкләр ясау. “Әти белән көчле мин”- балалар рәсемнәреннән күргәзмә<br>4.Район методик утырышын уздыру тәрбиячеләр белән берлектә | Тәрбияче.<br><br><br><br><br><br><br>Мөдир,Тәрбияче |
| **III.Әти-әниләр, мәктәп белән эш**<br>1.Ата-аналар җыелышы:”Балага бәйрәм оештыра белү сәнгате”<br>2. Ата-аналар белән әңгәмәләр.<br>– “Кышкы чорда балаларның сәламәтлеген саклау”.<br>-“Көндәлек тормышта очрый торган куркыныч предметлар”<br>-”Балагыз мәктәпкә әзерме” – ата-аналар өчен буклет әзерләү.<br>3. 1 класс укучылары белән “Күңелле стартлар” уены оештыру **мәктәп белән бергә**<br>4.Чыныктыру процедураларын дәвам итү<br>5.”Әлифба” бәйрәмендә катнашу | Тәрбияче.<br><br><br><br><br><br><br><br><br>Тәрбияче. |
| **IV.Административ-хуҗалык эшләре**<br>1.Җылылык режимын саклау, электр энергиясен экономияләү **мәктәп белән бергә** | Мөдир |


ЭЛЕКТРОННЫЙ ТАТАРСТАН

| | |
|---|---|
| 2.Туклануны оештыру эшен анализлау (нормаларның үтәлеше, ризыкның төрлелеге һәм әзерләү сыйфатын анализлау | |

**МАРТ АЕ**

| Эш төре | Җаваплы |
|---|---|
| **I.Кадрлар белән эш**<br>1.Производство киңәшмәсе.<br>–хезмәтне саклау һәм техника куркынычсызлыгы кагыйдәләренең үтәлеше. Рейд нәтиҗәләре белән таныштыру, инструктаж үткәрү<br>– 8 Март бәйрәмнәрен үткәрү турында сөйләшү<br>2.Оператив тикшерү.<br><br>**II.Педагогик оештыру эшләре**<br>1.”Әниләр алтын кебекләр”. Балалар рәсемнәреннән күргәзмә<br>2.8 Март – Халыкара хатын- кызлар көнен билгеләп үтү<br>3. 21 Март – Нәүрүз бәйрәме үткәрү<br>4. 22 март – Чиста су көне. Балалар белән әңгәмәләр үткәрү, экология бүлмәсен “Кеше тормышында су” темасына стендлар, күргәзмә материаллар белән баету<br>5.27 март – Халыкара театр көне. Каникулда театр көне үткәрү **мәктәп белән бергә**<br>6. Язгы каникуллар – “Сәламәтлек атналыгы”. Каникулга эш планы төзү<br>**III.Әти-әниләр, мәктәп белән эш**<br>1.”Яз көне балаларның сәламәтлеген саклау”.Әңгәмә, әти-әниләр почмагын мәгълүмат белән баету<br>2.Балаларның мәктәптә эшчәнлекләрен дәвам итү<br>3.”Нәүрүз”, 8 Март бәйрәмнәренә башлангыч класс укучыларын чакыру яки **мәктәп белән бергә**<br>4.Укучы балалар ярдәме белән уенчыклар төзәтү, курчак киемнәре яңарту<br><br>**IV.Административ-хуҗалык эшләре**<br>1.Балаларның авыру очракларына, туклану нормаларының үтәлешенә анализ<br>2.Бүлмәләрдә санитария-гигиена кагыйдәләренең үтәлеше, инвентарьның сакланышы (рейд)<br>3.Агымдагы эшләр | Тәрбияче.<br>Тәрбияче.<br>Тәрбияче.<br>Тәрбияче.<br>Тәрбияче.<br>Тәрбияче. |


ЭЛЕКТРОННЫЙ ТАТАРСТАН

**АПРЕЛЬ АЕ**

| Эштөре | Җаваплы |
|---|---|
| **I.Кадрлар белән эш**<br>1.Производство киңәшмәсе.”Бакчаның матурлыгы – барыбызның да эше”.Өмәләр үткәрү, чәчәк һәм яшелчә орлыклары утырту, территорияне матурлау турында сөйләшү - **мәктәп белән бергә**<br>2.Җәйге чорда инфекцияләрдән саклану. Консультация – авыл фельдшры<br>3. Оператив тикшерү | медсестра |
| **II.Педагогик оештыру эшләре**<br>1.Мәктәпкә хәзерлек группасы балаларының әзерлеген тикшерү, эшчәнлектә булу<br>3.12 апрель – Космонавтика көне. Балалар белән әңгәмәләр уздыру, рәсем күргәзмәсе оештыру<br>4.26 апрель – Г.Тукайның туган көне. Бәйрәм иртәсе уздыру**- мәктәп белән бергә**<br>5.Әти-әниләр өчен “Ачык ишекләр” көне уздыру, балаларның белемнәре белән таныштыру, эшчәнлек карау | Тәрбияче.<br>Тәрбияче.<br>Тәрбияче. |
| **III.Әти-әниләр , мәктәп белән эш**<br>1.”Балагыз мәктәпкә барырга телиме?” Балаларның мәктәпкә әзерлеге турында әти-әниләр белән әңгәмә<br>2.Бинаны, территор **мәктәп белән бергә**<br>ияне җыештыруда әти-әниләрнең ярдәмен оештыру -<br>3.Бөек Җиңүнең 79 еллыгына, карата “Без сугыш теләмибез” рәсем һәм кул эшләре күргәзмәләре оештыру | Тәрбияче.<br>Тәрбияче. |
| **IV.Административ-хуҗалык эшләре**<br>1.Территорияне, бинаны җыештыру **- мәктәп белән бергә**<br>2.Чәчәк орлыклары утыртуда әти-әниләрнең ярдәмен оештыру<br>2.Документация белән эшләү<br>3. Агымдагы эшләр | Тәрбияче |

## МАЙ АЕ

| Эш төре | Җаваплы |
|---|---|
| **I.Кадрлар белән эш** | |
| 1.”Җәйге чорда бакчаның эшчәнлеге” – производство киңәшмәсе уздыру.Инструктаж үткәрү | |
| 2.Кече тәрбиячеләрнең җәйге сәламәтләндерү эшендә роле. Әңгәмә уздыру | |
| 3.Җәйге чорда санэпидрежимны саклау. | |
| 4. Оператив тикшерү | |
| **II.Педагогик оештыру эшләре** | Тәрбияче. |
| 1.Балаларның белемнәренә анализ . | Тәрбияче. |
| 2. 9 Май – Бөек Җиңү көне. Балалар белән тантаналы митингта катнашу, ветераннарны котлау | Тәрбиячеләр |
| 3. 16 май – музейлар көне. Музейга экскурсия. | |
| 4. 28 май – чик сакчылары көне.Батырлык турында әңгәмәләр | |
| 5.Педагогик киңәшмә. “Еллык эш нәтиҗәләре” | |
| – еллык эшкә анализ | |
| – Җәйге чорда мәктәп **бакчасы участогында** эшләү, балаларга экология һәм хезмәт тәрбиясе бирү. | Тәрбияче |
| – җәйге сәламәтләндерү буенча эш планы төзү һәм раслау (эшләсәк) | |
| – чыгарылыш кичәсен уздыру турында сөйләшү | |
| – “Хуш яраткан бакчабыз!”, Кече Сабантуй бәйрәмнәрен уздыру - **мәктәп белән бергә** | |
| | Тәрбияче. |
| **III.Әти-әниләр, мәктәп белән эш** | |
| 1.Ата-аналар җыелышы. “Уку елы нәтиҗәләре” | |
| – узган уку елына йомгак ясау, актив әти-әниләргә рәхмәт белдерү,җәйге сәламәтләндерү буенча эш планы белән таныштыру | Тәрбияче. |
| – “Гаиләдә балага физик тәрбия”. | Тәрбияче |
| – җәйге чорда балаларның куркынычсызлыгын тәэмин итү буенча таләпләр | |
| – Чыгарылыш кичәсен уздыру турында сөйләшү | |
| 2.Башлангыч класс укучыларының өлгереше белән кызыксыну, укытучы белән әңгәмә. | |
| 3.Чыгарылыш кичәсен, “Хуш яраткан бакчабыз” бәйрәмен үткәрү | |
| **IV.Административ-хуҗалык эшләре** | Тәрбияче |
| 1.Документлар белән эш | |
| 2.Туклануны оештыруга анализ ясау | |
| 3. Мәктәп бакчасындагы эшләү, | |
| 4.Уен мәйданчыгын төзекләндерү. | |

**БАЛАЛАРНЫ СӘЛАМӘТЛӘНДЕРҮ БУЕНЧА ЭШ ПЛАНЫ**

**I.Балаларны сәламәтләндерү юнәлешендәге бурычлар:**
1.Балаларның сәламәтлеген саклау һәм ныгыту, физик үсешен камилләштерү, организмның саклану функцияләрен ныгыту, физик һәм акыл эшчәнлеген үстерү
2.Балаларда төп хәрәкәт күнекмәләрен булдыру, яхшы физик әзерлеккә ирешү
3.Балаларда сәламәт яшәү, культура-гигиена күнекмәләре булдыру, физик һәм рухи камиллеккә омтылыш тәрбияләү.

Әлеге бурычларны хәл итү өчен бакчада түбәндәге шартлар бар:
– ачык һавада уен мәйданчыгы.

**II. Балаларның сәламәтлеген ныгытуда түбәндәге чаралар кулланыла:**
1.Тулы кыйммәтле туклану оештыру;
2.Чыныктыру процедуралары;
3.Физик әзерлекне үстерү
4.Көнлек режим, гигиена

**Туклануныоештыру үз эченә түбәндәгеләрне ала:**
– туклану режимын саклау;
– ризыкның калорияле лелеген, көнлек туклану нормаларын саклау;
– туклану гигиенасын тәэмин итү;
– ризыкларны витаминнарга баету, менюның төрлелеген тәэмин итү;
– ит, сөт, балык ризыкларын, яшелчә-җимешне җитәрлек күләмдә куллану

**Чыныктыру процедуралары** организмның саклык чараларын ныгыта, организмның тышкы тәэсирләргә, сезонлы үзгәрешләргә каршы торучанлыгын арттыра һәм баланың оптималь үсешен тәэмин итә. Чыныктыру эше түбәндәгеләрне үз эченә ала:
– иртәнге гимнастиканы даими үткәрү, җылы вакытларда ачык һавада үткәрү;
– бүлмәдә җиңелчә кием белән йөрү;
– баланың индивидуаль үзенчәлекләрен искә алып, сезонга карап киендерү;
– бүлмәләрдәге температура режимын саклау;
– җәй көне ялан аяк үләндә йөрү;
– прогулкаларны тиешле югарылыкта оештыру.

**Физик әзерлекне үстерү:**
– физкультура эшчәнлеген тиешле югарылыкта үткәрү, балаларның яшенә һәм мөмкинлекләренә туры килгән физик нагрузкалар куллану
– иртәнге гимнастиканы тиешле югарылыкта . көннең җылы вакытында ачык һавада үткәрү;
– йокыдан соңгы гимнастика;
– массаж сукмакларында шөгыльләнү;
– занятиеләрдә физкультминутлар куллану;
– ачык һавада уен мәйданчыкларында хәрәкәтле уеннар оештыру;

– балалар белән индивидуаль эш;
– медицина-профилактика эшләре алып бару, балаларның үсешен медицина контроле астында тоту
– эти-әниләр, хезмәткәрләр белән санитария-аңлатуэшләре, медицина консультацияләре алып бару.

**Көнлек режим, гигиена:**
– группа бүлмәләренә, уен мәйданчыкларына, җиһазларга булган СанПиН таләпләрен үтәү;
– көнлек режимны рациональ оештыру һәм саклау;
– балаларның тормышын һәм сәламәтлеген саклау өчен шатрлар булдыру;
– культура-гигиена күнекмәләре булдыру, үз-үзенә ярдәм күрсәтү, үзеңне хөрмәт итәргә өйрәтү;
– адаптация чорында балага аеруча игътибарлы булу, уңай психологик климат тудыру.

## VI. Алга таба бурычлар:

– балаларда үз сәламәтлегеңне саклау, физик хәлеңә бәя бирә белү, тән төзелеше, органнарның ни өчен кирәклеге турында белемнәр һәм күнекмәләр булдыру өстендә эшләргә;
– яхшы һәм яман гадәтләрне аера белергә һәм сакланырга өйрәтергә;
– чыныктыру эшен системалы алып барырга;
– йокыдан соң массаж келәмнәрендә йөрүне булдырырга, моның өчен эти-әниләргә төрле массаж келәмнәре ясап китерүне йөкләргә;
– туклануны файдалы һәм рациональ итеп оештырыга, яңа төр ризыкларны менюга кертү өстендә эшләргә;
– рухи һәм физик камиллеккә омтылучы сәламәт бала тәрбияләү юнәлешендә актив һәм нәтиҗәле эшләргә.

## Бәйгеләр

| № | Эшнең эчтәлеге | вакыты | Җаваплы кеше |
|---|---|---|---|
| | Уку елына әзерлек. | Август | Коллектив |
| | Иң яхшы җәяүле.<br><br>Транспортта йөрү кагыйдәләре. | сентябрь | Коллектив |
| | «Созвездие-Йолдызлык 2025» | Ноябрь | Тәрбияче |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | “**Родные истоки**” | октябрь | |
| | “Боз фигуралары патшалыгы”<br>мәктәп белән бергә | декабрь | Коллектив |
| | Кул эшләре  буенча конкурс<br>**Конкурс поделок** | декабрь | |
| | Рус халык әкиятләре буенча (балалар  ата-аналары белән берлектә ясаган) УМК<br>рәсем һәм кул эшләре  буенча конкурс | Март | Тәрбияче |
| | “Иң матур сыерчык оясы” | март | Тәрбияче |
| | “**Ел тәрбиячесе-2025”** конкурсында катнашу. | март | Тәрбияче |
| | “**Яшел ут**” конкусында катнашу. | февраль | Мөдир, тәрбияче |
| | Шигырь бәйгесе уздыру (татар  һәм рус телендә шигырьләрне сәнгатьле итеп яттан сөйләү). | апрель | Тәрбияче |
| | Татар халык әкиятләре буенча (балалар ата-аналары белән берлектә ясаган) УМК<br>рәсем һәм кул эшләре  конкурсына нәтиҗә | апрель | Тәрбияче |
| | «Лучшая организация образовательного процесса в ДОУ -2026» | май | Мөдир, тәрбияче |
| | | | |

# Дәвамчанлык буенча балалар бакчасы һәм мәктәп арасында 2025-2026 елга эш планы

| № | Эшнең эчтәлеге | Үткәрү вакыты | Җаваплы |
|---|---|---|---|
| **Оештыруэшләре** | | | |
| 1 | “Мәктәп һәм балалар бакчасы арасында дәвамчанлык” план буенча фикер алышу | Август | Укытучы, тәрбияче, мөдир |
| 2 | “Белем көненә” багышланган линейкада катнашу | Сентябрь | Укытучы, тәрбияче |
| 3 | Мәктәпкә экскурсияләр | Даими | Тәрбияче |
| 4 | Бәйрәмнәргә мәктәп коллективын чакыру | План нигезендә | Тәрбияче |
| 5 | Уку елының тәмамлануына багышланган линейкада катнашу | Май | Тәрбияче, укытучы |

**Балаларның юл-транспорт травматизмын кисәтү өчен балалар бакчасының 2025-2026 нче уку елына профилактик эше.**

| № | Мероприятие | Вакыты | Җаваплы |
|---|---|---|---|
| | Юл билгеләре белән танышуны дәвам итү:<br>“Юл билгеләре – минем дуслар!”әңгәмә<br>“Кызыл, сары, яшел” – күңел ачу кичәсе.<br>“Яшелут” конкурсындакатнашырга<br>1) Иң яхшы рәсемгә конкурс “Сакта тора....”.<br>2)” 01 номерын һәркем белә!”презентация карау<br>Юл йөрү кагыйдәләре буенча почмакны яңа пособиеләр, дидактик уеннар белән яңартырга.<br>“Игътибар-балалар» - рәсем конкурсы<br>Эшлекле уен.”Юлда йөри беләсенме?”<br>“Иң яхшы җәяүле!”<br>1) Иң яхшы рәсемгә конкурс “Юл билгеләре”.<br>“ Йомгаклау. “Дидактик уеннар” | | Тәрбияче<br>Тәрбияче<br>Бакча коллективы |



ЭЛЕКТРОННЫЙ ТАТАРСТАН